**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ЧАКМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ IX УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 16**

Олы Чакмак авылы «7» апрель 2021 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 25 октябрендәге 4 номерлы карарына үзгәреш кертү турында**

Мөслим муниципаль районының Олы Чакмак авыл җирлегенең норматив хокукый актларын «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2013 елның 06 мартындагы 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 27 октябрендәге 347 номерлы Федераль законга туры китерү максатларында, Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 25 октябрендәге 4 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3 бүлекнең 2 статьясына түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Җирле үзидарә органы җитәкчесе һәм муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәрнең урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Мөслим муниципаль районы**
**Олы Чакмак авыл җирлеге Башлыгы** **И.М.Габидуллин**